

Андый чаралар Россия кvләмендә, шул исәптән Мордовиядә дә vтә. Мәсәлән, Жинv музее vз сайтында «Очучы Михаил Девятаев» виртуаль кvргәзмәсен урнаштырды. Онлайн-экспозиция совет очучысынын легендар батырлыгынын 80 еллыгына багышланган. Ә Ленинград олкәсенен Сиверский шәһәр-чегендәге «Чкалов паркы» территориясендә якташларыбыз, Мордовиядә туганнар, дусларыбыз, Санкт-Петербург һәм Ленинград олкәсе администрациясе вәкилләре очрашты.       Очрашу Михаил Девятаев батырлыгынын 80 еллыгына багышлап vткән. 1945 елнын 8 февралендә легендар очучы, башка тугыз хәрби әсир белән, немец бомбардировщигында «Карлсхаген-I» концлагереннан (Узедом утравы) кача. Чарада Михаил Петрович Девятаев турында «Куып тотарга һәм юк итәргә» документаль фильмы кvрсәтелде, «Жәһәннәмнән качу» истәлекле билгесенә чәчәкләр салынды. Сәламләv сvзләре белән, башкалар белән бергә, Санкт-Петербург Милләтләр йортынын милләтара монәсәбәтләр бvлеге баш белгече Разия Орлова катнашты. Шулай ук чарада катнашучыларга Казаннан видеоэлемтә аша сәламләv сvзе белән Михаил Девятаевнын улы Александр Михайлович Девятаев морәжәгать итеп: «Бу безнен очен гаилә бәйрәме. 8 февральдә бу качу булмаса иде, гаилә дә булмас иде».

Фото: Санкт-Петербургтагы «Шумбрат» фондыннан